
*“2 татар мәктәбенә 110 яшь”*

## *Яңалык өчен көрәшүче шәхес*




Йөрәк җылысын кызганмыйча, барлык борчу-мәшәкатьләрне сабыр гына җиңеп, күңелләребезгә нур бирүче укытучыларыбыз зур хөрмәткә лаек. Мәктәпне тәмамлап, еллар үткәч тә без аларны сагынып искә алырбыз. Әнә бит, гимназия музеенда да укытучыларга рәхмәт белдереп язган күпме хатлар, истәлекләр саклана. Менә “Шәһри Чаллы” гәҗитенең 2006нчы елда чыккан 13нче саны. Гаҗитнең бу санында «Оя да, кыя да булды» дигән мәкалә басылган. Аны гимназиянең чыгарылыш укучылары мәктәпне тәмамлаганга 10 ел үткәч язганнар. “Яңалыклардан курыкмаучы, мәктәпне әйдәп баручы, аның данын Татарстанда гына түгел, чит илләргә дә җиткерүче, аталарча кайгыртучан Рәфкать Нурулла улы Муллинга рәхмәтләребезне җиткерәбез», - дип язалар алар 1990-1994 нче елларда директор булып эшләгән Рәфкать абый турында.

Тарихны өйрәнеп беләбез: узган гасырның 90нчы еллары - иң авыр үзгәртеп кору еллары.Күп укытучылар мәктәптән китәргә мәҗбүр булалар, бигрәк тә ир-ат укытучылар мәгариф өлкәсендә бик аз калалар. Ә Рәфкать Нурулловичны нинди көч саклап калган соң мәктәптә? Минем бу сорауга җавап табасым килде һәм музейда сакланган истәлекләрне, документларны өйрәнеп, Рифкать Мулинның тормыш юлы белән якыннаррак таныштым.

«Ул кайда гына булмасын,кайда гына яшәмәсен һәм эшләмәсен, һәрчак тынгысыз һәм милли җанлы,оста оештыручы, гаҗәеп кешелекле һәм гади булып кала бирде», - дип яза аның турында язучы һәм дәүләт эшлеклесе Разил Валиев. Рәфкать Нурулловичның тормышын никадәр күбрәк өйрәнсәм , шулкадәр күбрәк сораулар туа торды: милли җанлы шәхес нинди булла? Оста оештыручы нинди сыйфатларга ия? Кешелеклелек һәм гадилек нидән гыйбарәт? Рәфкать абый ни өчен укытучы һөнәрен сайлаган соң? Ул шагыйрь Разил Вәлиев, Алмаз Хәмзин кебек күренекле шәхесләрне тәрбияләп чыгарган Түбән Каманың 1нче мәктәбен тәмамлый. Алар бергә очрашсалар, һәрвакыт хезмәтләренә җаннары белән бирелгән тынгысыз укытучыларын сагынып искә алалар. Рәфкатьнең күңелендә бу игелекле һөнәргә булган мәхәббәтне укытучылары уята. Шуңа күрә озак уйлап тормый, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә.

Яшь укытучының тәүге хезмәт көне Татарстанның иң ерак авылларыннан берсендә –Түбән Уратмада директор урынбасары буларак башланып китә.

Яраткан хезмәтенә баш-аягы белән чумып, гөрләтеп эшләп яткан көннәрнең берсендә Рәфкать Нурулловичны Түбән Камага РОНОга чакырталар. “Сез ике елда Уратма мәктәбен республикада алдынгы урыннарга чыгардыгыз, шуңа күрә Сезне Каенлы мәктәбенә директорлыкка тәкъдим итәбез»,- диләр.

Яшь директор эшне Каенлы мәктәбендә газ кертүдән, мәктәп бакчасына җиләк-җимеш агачлары утыртудан башлый. Каенлы мәктәбе бакчасындагы агачлар, җиләк-җимеш, яшелчәләр, гөлчәчәкләр, су сиптереп торган фонтаннар район җи-тәкчеләрен дә хәйран калдыра.

Күпләр шәһәрдән фатир алырга омтылганда, Рәфкать Нуруллович Каенлыда төпләнеп калырга уйлый: зур булмаган агач йорт сатып ала һәм гомере буе шушы нигезеннән аерылмый.

Авылга яшь һәм милли рух биреп торган, үзендә мәгърифәтче Тәҗетдин Ялчыгол эзләрен саклаган мәчетне сүтәргә карар чыгарылгач, Рәфкать абый каршы чыга, аны авыл аксакаллары да хуплый.

Шулай итеп, Каенлыда мәчет сакланып кала, авыл халкы бу изге эшләре өчен Рәфкать Нурлловичка зур рәхмәтле. Юкка гына исемен мәңгеләштерү йөзеннән 2012 нче елда Каенлы мәктәбенә Рәфкать Нуруллович Муллин исеме бирелмә-гәндер.

Өч ел эчендә Каенлы мәктәбен иң алдынгылар рәтенә чыгарган әле утыз яше дә туларга өлгермәгән директорны тагын Түбән Камага чакырталар. Бу юлы аның җилкәсенә йөкнең авыррагын салалар - район халык мәгариф бүлегенә мөдир итеп куялар. Бу эштә дә, гадәтенчә, янып-көеп, үҗәтләнеп эшли.Ун елдан артык гомерен бирә ул бу хезмәткә.

Шул вакыт эчендә районда ун урта мәктәп,егермеләп сигезьеллык мәктәпләр төзелә. Рус мәктәпләрендә татар теле укытыла башлаган икән - бу да аның тырышлыгы.

Түбән Камадан Чистайга юнәлгән юл читендә яшел ябалдашларын изәп, зифа каеннар үсә. Бу - Рәфкать Нуруллович каеннары. Уннарча чакырымнарга сузылган ул агачларны Каенлы, Афанас, Кызыл Чапчак укучылары белән бергәләп утырталар алар.

РОНО йөген ун ел тартканнан соң, аны район Советы башкарма комитеты рәисе урынбасары итеп сайлап куялар. Мин Рәфкать Нурулловичның тормышы, эшчәнлеге белән никадәр күбрәк таныша барсам, шуның кадәр аның тынгысыз, милләт өчен янып-көеп йөрүче, киләчәккә карап фикер йөртүче кеше икәнлегенә ышана бардым.

Район башкарма комитетында эшләгәндә күп кешене йортлы итә ул.Танылган төзүче Марат Шакирович Бибишев белән бергәләп, Каенлы, Кызыл Чапчак, Юга-ры Уратма авылларында йортлар салдыралар.

Районда мәчетләр төзелешенә дә күп көче керә Рәфкать Нурулловичның. Яшь-

тән үк оста курайчы, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры сәхнәләрендә дә биеп йөргән, язу сәләтенә дә ия.

Булдыклы Рәфкать абый нишләп һаман да мәгарифкә, балалар белән эшләргә тартылган соң? Башкарма комитетта да калмаган,башка җылырак урынга да китмәгән. Югыйсә, яхшы урыннар тәкъдим итәрлек дуслары да күп булган бит. Разил Вәлиев та нәкъ шул сорауны биргән аңа: “ Саный китсәң, дөньяда син булдырмаган бер эш тә юктыр кебек… Әмма син бу сәләтләреңнең берсен дә төп һөнәрең итеп сайламадың. Син тора-бара укытучы, педагог, мәгариф өлкәсендә оеш-тыручы буларак танылдың, гомереңне шул эшкә багышладың. Югыйсә, синнән менә дигән каләм әһеле яисә сәхнә остасы чыккан булыр иде. Ни өчен мәгариф өлкәсенә кереп чумарга булдың син, Рәфкать туган?

Рәфкать Нуруллович бу сорауга болай дип җавап бирә: “Рәфкать Муллин мөгәллим булып китмәсә, һичшиксез, татарның Мәхмүт Әсәнбаевы булыр иде»,- дип шаярткан иде Марсель Галиев. Бу шаяртуда ни дәрәҗәдә хаклык бардыр, белмим, әмма Мәхмүт Әсәбаевка багышлы бер җыр язганымны хәтерлим: «Җыелыгыз бергә, аксакаллар, Җыелыгыз, Кавказ, Рәсәйдән.

Караморзаларга җиткерегез-Без күргәнне илдә кем күргән?! Әй биетте безне ачы язмыш, Кыл өстенә басып биедек. Биюнең дә олы мәгънәсе бар - Халкыбызны саклау иң элек.»

Менә шул халык язмышы, ил язмышы турында борчылулар китергәндер инде безне мәгариф өлкәсенә… “ Мәгърифәт - азатлык юлында беренче адым», - дигән Гаяз Исхакый.

Аннары хәдисләрдә: “Мөселман кеше белемгә өйрәнеп,белгәнен дин кардәш-ләренә өйрәтсә, шул сәдаканың иң яхшысы булыр», - диелгән бит. Саваплы эш дип сайладым мин мәгарифне, ә бәлки мәгариф мине үзе сайлагандыр. Чөнки укытучы, мөгәллим кеше һәр өлкәдән дә күпмедер дәрәҗәдә мәгълүматлы булыр-га тиеш».



Күренекле язучы-публицист, Г. Тукай премиясе лауреаты Марсель ага Зарипов һәм мәгариф ветераны Нәкый ага Әхмәтшин белән.

Рәфкать Нуруллович Татарстан мәгариф министрлыгында эшләгән дәвердә аның турыдан-туры катнашы белән Казанда өч татар гимназиясе ачыла, Чаллының Мулланур Вахитов исемендәге 2нче мәктәп җирлегендә татар гимназиясе ачу да аңа йөкләнә. Ә биредә халык мәгариф идарәсе һәм татар иҗтимагый үзәге биш кандидат арасыннан үзен үк директор итеп сайлап та куялар. 45нче мәктәп һәм Вахитов мәктәбе коллективларыннан формалашкан укытучылар коллективын бер максатка туплау җиңел булмый.

«Сабыйлар, ата-ана һәм укытучы рәнҗешеннән дә авыр нәрсә юктыр, безне хаталардан Алла сакласын»,- ди ул, шуңа күрә эшләү дәверендә һәркем өчен дә уңай вариант табарга тырыша. Директорның эше үзе җитәкчелек иткән гимназия белән генә чикләнми. Рәфкать Нуруллoвичның тырышлыгы белән Чаллыда 54нче мәктәп-гимназия, 5нче татар мили музыка мәктәбе һәм төрек-татар колледжы ачыла. Түбән Камадагы Габдулла Тукай исемендәге төрек-татар колледжын ачуны оештыруда да Рәфкать Нуруллович башлап йөри.

«Чаллыда эшләгән туксанынчы елларны сагынып искә алам»,- дип яза Рәфкать Нуруллович үзенең «Дусларымны барлыйм» дигән китабында һәм ул елларда эшләгән укытучыларга чиксез рәхмәтен белдерә: “Алар иң авыр вакытларда, үз эшләрен төгәл һәм матур башкардылар. Ир егетләрдән Әдип Әмирхан улы Хәйдаров, Ренат Гапдрахман улы Каюмов,Назфат Хәйруллин, Шамил Гәрәев, Риф абый Якупов, Ильяс Шәмсиев, Илдус Гыйлаҗев, Әмир Дәминов, Наил Гыйззәтуллин, Венер Усманов, Сирин Шәйхетдинов, Зөфәр Галләмов кебекләрне аеруча санап китү кирәктер,чөнки мәктәптә ир-ат аз! Ә ир-егетләрсез мәктәпләребезнең дә, гимназияләребезнең дә гайрәте сүрелә, көрәшчеләр тәрбияләү кими»,- ди ул.

Тормышта, димәк, көрәшчеләр кирәк. Рәфкать Нуруллович үзе-чын көрәшче. Милләт өчен, аның киләчәге өчен, яңалык өчен көрәшүче шәхес.

«Гыйлем алуда халыкара стандартлар булырга тиеш, ләкин уку йортларында стандарт кешеләр һәм стандарт халыклар тәрбияләнергә тиеш түгел.Татарча укытуны мили мәгариф системасы белән бутарга ярамый.

Безгә көнбатыш технологиясен, көнчыгышның әхлагын бергә туплаган үзебезнең татар мәгариф системасы кирәк»,- ди ул.Менә шуңа күрә дә шәхестә милли рух тәрбияләү өчен шартлар тудырырга тырыша, хезмәт тәрбиясенә зур әһәмият бирә: татар халкы тарихын, милли йолаларын, гаиләдәге милли тәрбияне, гарәп графикасы нигезләрен, төрек телен өйрәнүгә, рәсем һәм музыка дәресләрен милли үзенчәлекләр белән баетылган программалар буенча укытуга, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә сүз тәмен тоя белү алымнары өстендә эшләүгә басым ясарга, гимназиядә автодело, шахмат, ритмика кабинеты җиһазлауга, мили киемнәр булдыруга, халкыбызның күренекле шәхесләре белән тыгыз элемтәдә торып эшләүгә әһәмият биреп эшли.



Р.Муллин 2 гимназия укытучылары арасында

Чаллыда Мулланур Вахитов исемендәге гимназиядә эшне җайга салгач, Татарстан Мәгариф министрлыгы Рәфкать Нурулловичны Түбән Кама педагогия училищесы директоры итеп билгели.



Россиянең атказанган укытучылары - “ Почет билгесе” орденлы Хәмит Рәхмәтуллин, “Хезмәт Кызыл байрагы” ордены кавалеры 2 мәктәпнең элекке директоры Нәкый Шәйхетдинов һәм Рифкать Муллин

Рәфкать абый эшләгән җирдә һәрвакыт яңалык килеп керә, чөнки ул башкача яши алмый. Түбән Кама педагогия училищесына Рәфкать Нуруллович директор булып эшкә килгәндә нибары бер татар группасы була, ә берничә елдан аларның саны 11гә җитә. Әнә шулай училищега да милли рух иңә. Бу кайберәүләргә , бәлки, ошап та бетмәгәндер. Әмма Рәфкать абый фәкать яшьнәп кенә яши ала.

«Ходай безгә җан биргәндер Изге эшләр кылырга. Кыйблабызны югалтмыйча

Кеше булып калырга»,- дип яза ул «Гомер бит ул бер генә» дигән шигырендә. Рифкать Нуруллович инде безнең арада юк. Тик халык күңелендә якты образы һәм матур эшлә-ре яши.



Татарстан Мәгариф һәм фән министры урынбасары Данил Мәхмүт улы Мостафин хөкүмәтебез бүләген тапшыра.

Халиуллина Айгөл, 2 гимназиянең 9 А сыйныфы укучысы.